ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

«15» август 2019 ел № 1159

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

«Керлигачское карьеруправление» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 16:25:110302:117, 16:25:110302:114 җир участокларына карата, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең категориясен үзгәртү турындагы мөрәҗәгатен карап тикшергәннән соң, шулай ук территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең гамәлдәге генераль планын актуальләштерү зарурилыгы белән бәйле рәвештә, шулай ук аның материалларын Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләренә туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы, "Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында" 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләргә керешергә.

2.Финанс эшләрен проектлау «Керлигачское карьеруправление» ҖЧҖ хисабына.

3. «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына проектны әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4.Әлеге карарны җирлек Уставындагы тәртип буенча Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында http://Leninogorsk.tatar.ru һәм «Лениногорские вести» газетында бастырырга.

5.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Н.Р. Залаков

А.Н. Карасев
5-28-28